**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЗАРЕЧЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЗАРЕЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Заречный поселогы **КАРАР**

«30» октябрь 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Торнаяс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 14 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Торнаяс авылы, Урман урамы, 26нчы йорт адресы буенча урнашкан Торнаяс авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районының Торнаяс авылында Урман урамында урамның так санлы йортларда 1-57 һәм урамның җөп санлы ягындагы йортларда 2-62 яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2019 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Торнаяс авылы, Урман урамы буенча, 73нче йорт янында Нурлат муниципаль районының Торнаяс авылында Урман урамында урамның так санлы йортларда 59-79 һәм урамның җөп санлы ягындагы йортларда 64-104 яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Торнаяс поселогында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Торнаяс поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм әлеге кертемнәрне түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

- Торнаяс авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Торнаяс авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Заречный авыл җирлеге башлыгы Низамиев З.Х